Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районы
муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
“7 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”

«Каралды»
Педагогик киңәшмә
утырышында

Беркетмә №1 «30 » августтан 2023 ел.

«Расланды»
Беркетмә №79 «30 » августтан 2023 ел.

Директор
_________М.Г. Макарова /

**Туган телдән (татар теле), туган телне (татар телен)**
**туган тел буларак өйрәнүчеләр өчен**
**эш программасы**

Белем бирү баскычы: башлангыч гомуми, 1-4 нче сыйныфлар

**Башкарылды**: башлангыч сыйныф укытучыларының
мәктәп методик берләшмәсе

Менделеев шәһәре, 2023 ел

Түбәндәге дәреслекләр аша гамәлгә ашырыла:

| Сыйныф | Дәреслек авторлары | Нәшрият |
|---|---|---|
| 1 | И.Х. Мияссарова, Ф.Ш. Гарифуллина, Р.Р. Шәмсетдинова Әлифба.<br>И.Х.Мияссарова, Ч.М.Харисова Татар теле. | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| 2 | И.Х.Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| 3 | И.Х.Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |
| 4 | И.Х.Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова | Казан,“Мәгариф – Вакыт” |

Эш программасы барлыгы: 270 сәгать (1сыйныф – 66 сәг., 2 сыйныф – 68 сәг., 3 сыйныф – 68 сәг., 4 сыйныф – 68 сәг.)

**Татар телен туган тел буларак укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре**

**1нче сыйныф**

**Шәхси нәтиҗәләр**

**Укучыларда түбәндәге шәхси кыйммәтләр формалаша:**
"Гаилә”, "Туган ил”, "мәрхәмәтлелек”, "башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү;
-туган республикага, гаиләгә, туганнарга карата хөрмәт, әти-әнине ярату; үз милләтеңне ярату, татар булуың белән горурлану;
-укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү;
**Укучыларга** түбәндәгеләрне **формалаштыру мөмкинлеге бирелә:**
-әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләрен һәм геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү,
-әйләнә-тирәдәге табигатькә, тормышка дөрес мөнәсәбәт булдыру,
- куркынычсыз, сәламәт яшәү рәвеше алып бару,
-материаль һәм рухи кыйммәтләргә сакчыл караш формалаштыру.

**Предметара нәтиҗәләр.**

**Регулятив универсаль уку гамәлләре.**
**Укучы** түбәндәгеләрне **үзләштерә:**
-эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.
-укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү.
-укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү.
-эш сыйфатына бәя бирә белү.
-эш барышында гади генә эш приборлары белән эш итә белү ( линейка, бетергеч, карандаш).
**Укучыларга** түбәндәгеләрне **формалаштыру мөмкинлеге бирелә:**
-укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белергә;
-эш сыйфатына бәя бирә белергә,
- укытучы ярдәме белән уку проблемасын табарга һәм формалаштырырга;
-укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга;
-укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерергә;

**Танып белү универсаль уку гамәлләре.**
**Укучы** түбәндәгеләрне **үзләштерә:**
-дәреслек белән эш итә белү.
-хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.
-этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку.
-текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.
-текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
-укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.
-предметларны, чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгеле белү.

-аваз белән хәрефне аера белү.
**Укучыларга** түбәндәгеләрне **формалаштыру мөмкинлеге бирелә:**
-сүз басымы, исем , сыйфат, фигыль кебек сүз төркемнәре турында башлангыч мәгълүмат алу.
сөйләм берәмлеге буларак җөмлә, аларны төрле интонация белән әйтү, сүзләрдән җөмләләр, җөмләләрдән кечкенә хикәяләр төзи белү.
**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре.**
**Укучы** түбәндәгеләрне **үзләштерә:**
- дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү
- укытучының, классташларның сорауларына җавап бирү;
- сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.
- башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
**Укучыларга** түбәндәгеләрне **формалаштыру мөмкинлеге бирелә:**
-әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аралаша белү;
-парлап һәм күмәк эшләү.

**Предмет нәтиҗәләре.**

**«Авазлар һәм хәрефләр » бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә**:

- аваз һәм хәрефләрне аерырга өйрәнә, хәрефләрдән иҗекләр төзү;
-татар алфавитындагы хәрефләрнең санын, тәртибен, исемнәрен белү һәм язуда дөрес күрсәтү;
-сузык һәм тартык авазларны аера белү, дөрес уку, язу.
-сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан-юлга күчерү.

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала**:
-сүзләргә фонетик-график анализ (аваз-хәреф анализы) ясый белү.-калын һәм нечкә сузыкларны, яңгырау һәм саңгырау тартыкларны чагыштыра һәм аера белергә, сүзгә фонетик анализ ясарга өйрәнү.

**«Орфоэпия» бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә**:
-телдән сөйләмне дөрес итеп төзи белү;
-татар теленең үзенчәлеклесузык һәм тартык авазларын дөрес әйтә белү.
-аңлап һәм сәнгатьле итеп уку.
-сүз басымын дөрес кую.

**«Морфология» бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә**:
-җөмләләрдән предметларны , аларның эшен-хәрәкәтен һәм билгесен белдергән сүзләрне аерып таный белү һәм сөйләмдә дөрес куллану;

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала**:
-фигыльләрнең барлык-юклык формаларын дөрес куллану.

**«Синтаксис» бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә**:
-сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзи белү;
-җөмлә ахырында тыныш билгеләрен куя белү;
-тәрҗемә итү.

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала**:
-сөйләм барлыкка китерүдә җөмләнең ролен аңлау.

**2нче сыйныф**
**Шәхси нәтиҗәләр**

**Укучыларда түбәндәге шәхси кыйммәтләр формалаша:**

-"Гаилә", "Туган ил", "мәрхәмәтлелек", "башкаларга карата түземлелек" төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү;
-туган республикага, гаиләгә, туганнарга карата хөрмәт, әти-әнине ярату; үз милләтеңне ярату, татар булуың белән горурлану;
-укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү;
**Укучыларга** түбәндәгеләрне **формалаштыру мөмкинлеге бирелә:**
-әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләрен һәм геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү.

**Предметара нәтиҗәләр.**

**Регулятив универсаль уку гамәлләре.**
**Укучы** түбәндәгеләрне **үзләштерә:**
-Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.
- Укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү.
-Укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү.

**Укучыларга** түбәндәгеләрне **үзләштерү мөмкинлеге бирелә:**

-Эш сыйфатына бәя бирә белү.
-Эш барышында гади генә эш приборлары белән эш итә белү ( линейка, бетергеч, карандаш).

**Танып белү универсаль уку гамәлләре.**
**Укучы** түбәндәгеләрне **үзләштерә:**
-Дәреслек белән эш итә белү.
-Хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.
-Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку.
-Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.
-Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
-Укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.
- Предметларны, чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү.
-Укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген сөйли белү.
-Авазлар һәм хәрефләр турындагы мәгълүматны тулыландыру.

**Укучыларга** түбәндәгеләрне **үзләштерү мөмкинлеге бирелә:**
-Авазларның әйтелешен әдәби тел нормалары буенча өйрәнү.
-Телебезнең төп фонетик законын – сингармонизмны да өйрәнү.
**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре.**
**Укучы** түбәндәгеләрне **үзләштерә:**
- Дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү
- Укытучының, классташларның сорауларына җавап бирү;
- Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.
**Укучыларга** түбәндәгеләрне **үзләштерү мөмкинлеге бирелә:**
- Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
- Парларда эшли белү.

**Предмет нәтиҗәләре**

**«Фонетика. Графика» бүлеге**

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә**:

- аваз һәм хәрефләрне аерырга өйрәнә;
- татар телендәге авазларга характеристика бирә: сузык авазларның калын һәм нечкә булуы, тартык авазларның яңгырау һәм саңгырау төрләргә бүленүе күрсәтелә, аларга бәйле төп фонетик законнар ( сингармонизм, ирен гармониясе турында) төшенчә бирелә;

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала**:
-сүзләргә фонетик-график анализ (аваз-хәреф анализы) ясый, дәреслектәге үрнәк буенча сүзләрне мөстәкыйль рәвештә тикшерә һәм аның дөреслеген дәлилли.

**«Сүз төзелеше (морфемика)» бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә**:
-сүзнең тамырын билгели;
-төрле сүз төркемнәрен ясаучы кушымчаларны таба һәм күрсәтә;
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала**:
-мәгънәле кисәкләрнең чикләре ачык күренеп торган сүзләрнең дәреслектә бирелгән күләмдә төзелешен тикшерә(тамырын, булса – ясагыч кушымчаларын, нигезенбилгели);
**«Морфология» бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә**:
-исемнәрнең мәгънәсен, сорауларын, грамматик билгеләрен(берлек һәм күплек сан формаларын, килеш һәм тартым белән төрләнүен) үзләштерә;
- микъдар һәм тәртип саннарының мәгънәсен, сорауларын өйрәнә;
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала**:
-зат алмашлыклары, кайбер рәвешләр, бәйлекләр турында мәгълүмат ала;
-тәкъдим ителгән тексттан (җөмләдән) өйрәнелгән сүз төркемнәрен таба.
**«Синтаксис» бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә**:
- сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне бер-берсеннән аерырга өйрәнә;
-сораулар куеп, сүзтезмәдәге һәм җөмләдәге сүзләр арасында мәгънә бәйләнешен ачыклый;
-җөмләләрнең әйтү максаты буенча төрләрен(хикәя, боеру, сорау) билгели;
-җөмләдәге тойгылы һәм тойгысыз интонацияне аера;
-җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен таба;
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала**:
-аергыч, тәмамлык һәм хәлләрне аера;
- гади җөмләләргә дәреслектә бирелгән материал күләмендә синтаксик анализ ясый(җөмлә кисәкләрен билгели), тикшерүнең дөреслеген бәяли;

**«Орфография һәмпунктуация» бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә**:
-дөрес язу кагыйдәләрен өйрәнелгән күләмдә файдалана;
- сүзнең дөрес язылышын орфографик сүзлектән карап билгели;
- 30-40сүзле текстны хатасыз итеп күчереп яза;
-өйрәнелгән кагыйдәләргә туры килгән 20-25 сүзле текстны диктант итеп яза;
- үзе язган яки бирелгән тексттагы орфографик һәм пунктуацион хаталарны таба һәм төзәтә.
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала**:
-орфографик хатаның килеп чыгардай урынын белә;
-тиешле орфограммага туры килгән мисалларны сайлый;
-текст төзегәндә, аны орфографик һәм пунктуацион хаталар җибәрмәстәй итеп үзгәртә ала;
**« Сөйләм үстерү» бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә**:
-дәрестә, мәктәптә, тормыш-көнкүрештә, төрле яшьтәге таныш яки таныш булмаган кешеләр белән телдән аралашканда, тел берәмлекләрен урынлы файдалана;
- көндәлек тормышта сөйләм әдәбе һәм телдән аралашу нормаларын саклый (әңгәмәдәшен тыңлый белә, дөрес сүзләр белән җавап бирә, сөйләшүне дәвам итә ала);
- сөйләм вакытында үз фикерен яклый белә, аның дөреслеген дәлилли;
- текстка исем бирә;
- хат, открытка яки записка кебек зур булмаган текстлар яза.
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала**:
-текстның эчтәлеген башка зат (үтәүче) исеменнән сөйли;
-аерым темага караган сурәтләү, хикәяләү характерындагы хикәяне телдән төзи.

## 3нче сыйныф

**Шәхси универсаль уку гамәлләре:**
**Укучы түбәндәгеләрне үзләштерә:**
-"Гаилә", "Туган ил", "мәрхәмәтлелек", "башкаларга карата түземлелек" төшенчәләрен кабул итү,

аларның кадерен белү;
-туган республикага, гаиләгә, туганнарга карата хөрмәт, эти-әнине ярату; үз милләтеңне ярату, татар булуың белән горурлану;

**Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:**

-укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү;
-әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләрен һәм геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре**
**Укучы түбәндәгеләрне үзләштерә:**

- Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.
- Укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү.
- Укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү.
- Эш сыйфатына бәя бирә белү.

**Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:**

- Эш барышында гади генә эш приборлары белән эш итә белү ( линейка, бетергеч, карандаш).

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**
**Укучы түбәндәгеләрне үзләштерә:**

- Дәреслек белән эш итә белү.
- Хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.
- Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку.
- Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.
- Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
- Укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.
- Предметларны, чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү.
- Укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген сөйли белү.

**Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:**

- Авазлар һәм хәрефләр турындагы мәгълүматны тулыландыру.
- Авазларның әйтелешен әдәби тел нормалары буенча өйрәнү.
- Телебезнең төп фонетик законын – сингармонизмны да өйрәнү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**
**Укучы түбәндәгеләрне үзләштерә:**

- Дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү
- Укытучының, классташларның сорауларына җавап бирү;
- Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.

**Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:**

- Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
- Парларда эшли белү.

**Предмет нәтиҗәләре:**

**«Сүз » бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**

-сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәсен, күп мәгънәле булуын аера;
-синоним, омоним, антоним сүзләрне дөрес билгеләп, аларны сүтезмә һәм җөмлә төзегәндә куллана;

**Укучыга түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеге ала:**

-төрле типтагы сүзлекләр белән эшли;
-сүзләрне мөстәкыйль рәвештә тикшерә һәм аның дөреслеген дәлилли.

**«Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы» бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**

-сүзнең тамырын билгели;

-съз тцзелешен тикшеү күнегүләрен үти;
-тамырдаш сүзләрне сүз формаларыннан аера белә.
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала**:
-мәгънәле кисәкләрнең чикләре ачык күренеп торган сүзләрнең дәреслектә бирелгән күләмдә төзелешен тикшерә(тамырын, булса – ясагыч кушымчаларын, нигезенбилгели);
-тикшерелгән сүзнең дөреслеген билгели белә.

**«Морфология» бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**
-исемнәрнең мәгънәсен, сорауларын, грамматик билгеләрен(берлек һәм күплек сан формаларын, килеш һәм тартым белән төрләнүен) үзләштерә;
- микъдар һәм тәртип саннарының мәгънәсен, сорауларын өйрәнә;
- фигыльләрнең мәгънәсен, сорауларын, барлык-юклык, хәзерге, үткән, киләчәк заманнар, зат-сан формаларын билгели.
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала**:
-зат алмашлыклары, кайбер рәвешләр, бәйлекләр турында мәгълүмат ала;
- өйрәнелгән сүз төркемнәренә дәреслектә бирелгән материал күләмендә морфологик анализ ясый, аның дөреслеген бәяли;

**«Синтаксис» бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**
- сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне бер-берсеннән аерырга өйрәнә;
- сораулар куеп, сүзтезмәдәге һәм җөмләдәге сүзләр арасында мәгънә бәйләнешен ачыклый;
- җөмләләрнең әйтү максаты буенча төрләрен(хикәя, боеру, сорау) билгели;
- җөмләдәге тойгылы һәм тойгысыз интонацияне аера;

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**
-аергыч, тәмамлык һәм хәлләрне аера;
- гади җөмләләргә дәреслектә бирелгән материал күләмендә синтаксик анализ ясый(җөмлә кисәкләрен билгели), тикшерүнең дөреслеген бәяли;
- гади һәм кушма җөмләләрне аера.

**« Сөйләм үстерү» бүлеге**
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**
-дәрестә, мәктәптә, тормыш-көнкүрештә, төрле яшьтәге таныш яки таныш булмаган кешеләр белән телдән аралашканда, тел берәмлекләрен урынлы файдалана;
- көндәлек тормышта сөйләм әдәбе һәм телдән аралашу нормаларын саклый (әңгәмәдәшен тыңлый белә, дөрес сүзләр белән җавап бирә, сөйләшүне дәвам итә ала);

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала**:
- текстның эчтәлеген башка зат (үтәүче) исеменнән сөйли;
- аерым темага караган сурәтләү, хикәяләү характерындагы хикәяне телдән төзи;
- җөмләдәге урыннары алышынган сүзләрне дөресли, сүз тәртибен мәгънәсенә карап үзгәртә;
- сөйләм әдәбе сакланмаган текстларны төзәтә;

## 4нче сыйныф

## 4 нче сыйныф
### Шәхси нәтиҗәләр

Чыгарылыш сыйныф укучысында формалашачак:
- физик һәм психик сәламәтлекне саклау;
- татар телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш;
- тел аша әйләнә-тирә тормышка игътибар, дөрес мөнәсәбәт булдыру;
- фикерләү сәләтен үстерү;
- үзенә һәм башкаларга бәя бирүенә, үз-үзен тәрбияләвенә ирешү;
- татар теле фәненә танып белү кызыксынуы;
- дәреслек геройларына һәм партадаш күршеңә ярдәм итү инициативасы;
- үз уңышларың,уңышсызлыкларыңның сәбәпләре турында фикер йөртү;

- нормалардан тайпылышны күрү;
- өстәмә мәгълүмат алу өчен, белешмә чыганаклардан мөстәкыйль файдалана алу; предметара нәтиҗәләре:
- гомуми уку кунекмәләре һәм үз эшчәнлегеңне оештыра алу сәләтләре;
- үз эшчәнлегеңне планлаштыру, аны контрольдә тоту һәм бәяли белү күнекмәләре.
*Чыгарылыш сыйныф укучысы формалашу өчен мөмкинлек алачак:*
*- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш һәм аны яхшы өйрәнү теләге;*
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
*- текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;*
*- “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек” төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр.*

**Метапредмет нәтиҗәләр**

**Танып-белү универсаль уку гамәлләре:**

Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:
- тел чараларының төрле жанрдагы әсәрләрдә кулланылу үзенчәлекләрен күрә белергә;
- тел материалын уку материалы белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәткә;
- татар һәм рус телләренең уртак һәм аермалы якларын күрә белергә,сөйләм барышында ике тел чараларын бутамаска;
- татар теленә рус теленнән һәм рус теле аша башка телләрдән кергән лексик чараларны аеруга игътибар юнәлтергә;
- татар теленнән алган белемне башка фәннәрне үзләштерүдә файдалана белергә.
*Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнергә мөмкинлек алачак:*
*- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белергә;*
*- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләргә, аларны чишү өчен алгоритм булдырырга;*
*- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләргә;*
*- төп мәгълүматны аерырга, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белергә;*
*- тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар кулланырга.*

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:
- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңларга, аңа туры килерлек җавап бирә белергә;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзергә;
- аралаша белү сәләтен үстерергә (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белергә;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкарырга;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белергә.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

Чыгарылыш сыйныф укучысы өйрәнәчәк:
- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белергә;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белергә;
- **уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрол**ьгә ала белергә;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белергә;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белергә;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштырырга;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белергә.

**Предмет нәтиҗәләре**

**<u>Орфография һәм пунктуация</u>**

**Укучы өйрәнәчәк:**

-дөрес язылыш кагыйдәләрен өйрәнгән күләмдә куллана;
-80-90 сүзле текстны дөрес итеп күчереп яза;

-үзе төзегән һәм тәкъдим  иткән текстны тикшерә, орфографик һәм пунктуацион хаталарны таба һәм төзәтә;
-аваз һәм хәрефләрне аера;
- ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчелекләрен аңлый, авазларга характеристика бирә ала;
- хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм, кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны куллана ала.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-орфографик хата ясау мөмкинлеге булган очракларда аңлау, аерым орфограммаларга мисаллар сайлау, текстлар төзегәндә орфографик һәм  пунктуацион хаталарны булдырмау өчен, язганнарны үзгәртү, хаталар өстендә эшләгәндә, аларның сәбәпләренә төшенү һәм алдагы язма эшләрдә хата җибәрмәү юлларын ачыклау мөмкинлеге ала;
-үз сөйләмендә татар әдәби тел нормаларын саклый һәм әңгәмәдәшенең сөйләмендә бу нормаларның дәреслектә бирелгән материал күләмендә үтәлүен бәяли;
- сүзгә басым куйганда яки сүзнең дөрес әйтелешендә икеләнү туган очракта, дәреслектәге сүзлек буенча мөстәкыйль рәвештә җавап таба яки укытучысына һәм эти-әнисенә мөрәҗәгать итә ала.

**<u>Фонетика. Орфоэпия. Графика.</u>**

**Укучы өйрәнәчәк:**

-дөрес язылыш кагыйдәләрен өйрәнгән күләмдә куллана;
-80-90 сүзле текстны дөрес итеп күчереп яза;
-үзе төзегән һәм тәкъдим  иткән текстны тикшерә, орфографик һәм пунктуацион хаталарны таба һәм төзәтә;
-аваз һәм хәрефләрне аера;
- ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчелекләрен аңлый, авазларга характеристика бирә ала;
- хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм, кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны куллана ала.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-орфографик хата ясау мөмкинлеге булган очракларда аңлау, аерым орфограммаларга мисаллар сайлау, текстлар төзегәндә орфографик һәм  пунктуацион хаталарны булдырмау өчен, язганнарны үзгәртү, хаталар өстендә эшләгәндә, аларның сәбәпләренә төшенү һәм алдагы язма эшләрдә хата җибәрмәү юлларын ачыклау мөмкинлеге ала;
-үз сөйләмендә татар әдәби тел нормаларын саклый һәм әңгәмәдәшенең сөйләмендә бу нормаларның дәреслектә бирелгән материал күләмендә үтәлүен бәяли;
- сүзгә басым куйганда яки сүзнең дөрес әйтелешендә икеләнү туган очракта, дәреслектәге сүзлек буенча мөстәкыйль рәвештә җавап таба яки укытучысына һәм эти-әнисенә мөрәҗәгать итә ала.

**<u>Лексикология</u>**

**Укучы өйрәнәчәк:**

-мәгънәсе ачыклану таләп итеlә торган сүзләрне табарга;
-текст буенча сүзләрнең мәгънәсен аера яисә аны аңлатмалы сүзлек ярдәмендә ачыкларга өйрәнә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-текстларда кабатлаулар булдырмас өчен, кирәкле синонимнар, антонимнар табу, текстта туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне билгеләү, аларның урынлы кулланылышын бәяләү, тәкъдим ителгән сүзләр арасыннан тиешлесен сайлап алу мөмкинлеге ала.

**<u>Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы (морфемика)</u>**

**Укучы өйрәнәчәк:**

-тамырдаш сүзләрне һәм сүз формаларын аерырга;
-сүзнең тамыр һәм кушымчаларын (аффиксларын) табарга өйрәнә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча кушымчаларның чикләре ачык күренеп торган сүзләрнең төзелешен тикшерү һәм аның дөреслеген бәяләү мөмкинлеге ала.

**<u>Морфология. Сүз төркемнәре</u>**

**Укучы өйрәнәчәк:**

-исемнәрнең сан, килеш һәм тартым белән төрләнешен;
- сыйфатларның лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләрен;
-фигыльнең лексик-семантик үзенчәлекләрен өйрәнә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**
-дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча исемгә, сыйфатка, фигыльгә морфологик анализ ясау һәм аның дөреслеген бәяләү, тексттан алмашлык, рәвеш, бәйлек сүзләр, кисәкчә, теркәгечләрне, фигыльләрдәге юклык кушымчаларын (-ма / -мә) табу мөмкинлеге ала.

**Синтаксис**

**Укучы өйрәнәчәк:**
-җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аерырга;
-сораулар ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне табарга;
-җөмләнең әйтү максаты буенча төрен аерырга;
-җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә;
-тиңдәш кисәкле һәм тойгылы җөмләләрне интонациясе буенча билгеләргә өйрәнә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**
-җөмләнең иярчен кисәкләрен – аергыч, тәмамлык, хәлләрне аеру,дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча гади җөмләгә синтаксик анализ (җөмлә кисәкләре буенча) ясау һәм аны тикшерүнең дөреслеген бәяләү, гади һәм кушма җөмләләрне бер-берсеннән аеру мөмкинлеге ала.

**Бәйләнешле сөйләм үстерү**

**Укучы өйрәнәчәк:**
-аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайларга;
- көндәлек аралашуга бәйле татарча сөйләм әдәбе формаларын дөрес кулланырга;
-аралашу ситуациясен исәпкә алып, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерергә һәм аның дөреслеген дәлилләргә;
-текстка исем бирергә;
-укылган яки тыңлаган текстның планын төзергә;
-аерым аралашу ситуацияләренә туры китереп, хат яки тәбрикләү хаты кебек кечкенә текстлар язарга өйрәнә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**
-тәкъдим ителгән исемнең эчтәлегенә туры килгән текст төзү, бирелгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү, сөйләмнең сурәтләү, хикәяләү, фикер йөртү кебек төрләрен кулланып, билгеле бер тема буенча телдән хикәя төзү, урыннары алышынган җөмләләрдән торган текстны тикшерү һәм төзәтү, аның мәгънә бөтенлеге югалган урыннарын табу, хаталы текстларга төзәтмә кертү, төрле төрдәге изложение яки сочинение язганда, эшне эзлекле алып бару, аны тикшерү һәм бирелгән үрнәк белән чагыштыру, уку бурычларының дөреслеген бәяләү, үз текстын, аралашу максаты һәм шартыннан чыгып, чыганак (беренчел) текст белән чагыштыру, электрон чыганаклардан файдаланганда, тел нормаларының үтәлешен саклау мөмкинлеге ала.

## Укыту фәненң эчтәлеге

### 1 нче сыйныф (татар теле – 66 сәгать)

| № п/п | Бүлекләр, темалар | Укыту программасының төп эчтәлеге | Сәгать саны |
|---|---|---|---|
| 1 | **Грамотага әзерлек чоры** | Язуга куелган гигиена таләпләрен үзләштерү. Язганда бармакларның һәм кулларның хәрәкәтләнү үзенчәлекләрен үстерү. Дәфтәр битендә һәм сыйныф тактасында дөрес юнәлештә язу осталыкларын үстерү. Сүзне өйрәнү объекты һәм анализлау материалы буларак кабул итү. Сүзнең мәгънәсенә төшенү. Сүз һәм җөмләләрне аеру. Җөмләдән сүзләрне аеру, аларның тәртибен үзгәртү. | **16** |
| 2 | **Әлифба чоры, яки төп чор** | Хәрефләрдән иҗекләр төзү, аннан соң иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр төзеп уку. Укучыларда сүзтезмәләрдән җөмләләр төзү күнекмәләре тәрбияләү. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Эчтәлеген аңлап, кирәкле урыннарда паузалар белән | **32** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | сүз басымын дөрес куеп уку.<br>Әлифба чорында татар һәм рус телләрендә бердәй әйтелешле авазлар белән ([б], [п], [д], [т], [ж],[ш], [з], [с], [и], [й], [л], [м], [н], [р], [у], [ф], [ц], [щ]) танышу, алар кергән сүзләрне дөрес уку.<br>[а], [о], [э], [w], [гъ], [къ], [х], [ч], [ы] авазларының әйтелеш үзенчәлекләре һәм бу авазларны язуда дөрес күрсәтү.<br>Татар телендәге [ә], [ө], [ү], [җ], [ң], [һ] авазлары кергән сүзләрне, сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне дөрес уку. | |
| 3 | **Әлифбадан соңгы чор** | Алфавитны дөрес язу,уку.Аерым сүзләр белән җөмләләр төзеп язу. Текстны дөрес итеп күчереп язу<br>Телдән һәм язма сөйләм. Аралашу әдәбе. | **2** |
| 4 | **Авазлар һәм хәрефләр** | Алфавит. Баш хәрефтән языла торган сүзләр.<br>Сузык авазлар, аларның төрләре. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан-юлга күчерү. Басым.<br>Тартык авазлар, аларның төрләре.<br>Сузык һәм тартык аваз хәрефләрен дөрес уку һәм язу. | **5** |
| 5 | **Морфология** | Предметны, аның эшен, хәрәкәтен һәм билгесен белдергән сүзләр. Аларның мәгънәләрен аңлату, сорауларын әйтү. Фигыльләрнең барлык-юклык формалары турында төшенчә бирү. | **3** |
| 6 | **Синтаксис.** | **Сүздән җөмләгә.**Җөмләләр ахырында куела торган тыныш билгеләре турында гомуми мәгълүмат. Сөйләмне барлыкка китерүдә җөмләнең әһәмияте. Анда сүзнең кем яки нәрсә турында баруын һәм алар турында нинди яңалык хәбәр ителүен белдерә торган кисәкләрне билгеләү. Аерым сүзләрдән җөмләләр төзү, сүзләр арасындагы бәйләнешне аңлату.<br>Әзер тексттан сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу. Аннан соң аларны укытучы әйтүе буенча язу, ул тәкъдим иткән сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзеп язу.<br>Аерым темалар буенча өйрәнгән сүзләрне, сүзтезмә һәм җөмләләрне диктант итеп язу. Матур язу күнегүләрен үтәү. Сөйләм күнекмәләрен булдыру өстендә даими эшләү. | **4** |
| 7 | **Сөйләм үстерү** | Текст һәм аңа исеме туры килгәнен сайлап алу.<br>Җөмлә чикләрен билгеләү, җөмлә ахырына тыныш билгесен сайлау. Рәсем һәм бирелгән сүзләр буенча телдән хикәя төзү. Сүзнең мәгънәсен билгеләү (башта укытучы ярдәмендә). | **3** |
| 8 | **Ел буена үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау** | | **3** |
| **Барлыгы:** | | | **68** |

**2 нче сыйныф (татар теле – 68 сәгать)**

| № п/п | Бүлекләр, темалар | Укыту программасының төп эчтәлеге | Сәгать саны |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | **Кабатлау** | | **5** |
| 2 | **Фонетика,график а һәм орфоэпия** | Авазлар һәм хәрефләр.<br>Сузык авазлар һәм хәрефләр. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны дөрес әйтү. Сингармонизм законы. Сузык авазларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы.<br>Татар һәм рус телләрендә [а], [э], [о], [ө], [ы] авазларның әйтелеш үзенчәлекләре, бу сузыкларын белдерә торган хәрефләр һәм аларның дөрес язылышы.<br>*Я, ю, е* хәрефләре, алар кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу.<br>Тартык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Алар кергән сүзләрне дөрес әйтү һәм язу; [w], [гъ], [къ], [х], [ч] тартыкларын дөрес әйтү, аларны белдерә торган хәрефләрнең язылышы. Татар теленең үзенчәлекле тартыклары [ж], [ң], [һ]. Бу хәрефләр кергән сүзләрне дөрес язу күнекмәләре булдыру.<br>*Ц, щ* хәрефләре булган сүзләрне дөрес уку һәм язу.<br>*ъ* һәм *ь* хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу.<br>Сүзлек һәм аңлатмалы диктантлар язу. | **30** |
| 3 | **Сүз төзелеше (морфемика)** | Сүзләрне иҗекләргә бүлү.<br>Иҗекләрнең калынлыгы-нечкәлеге сузык авазларга бәйле булуы. Сүз басымы турында мәгълүмат бирү.<br>Сүз тамыры. Аны дөрес табарга өйрәнү. | **8** |
| 4 | **Морфология.** | **Исем**.Исемнең мәгънәсе, сораулары турында белгәннәрне ныгыту. Ялгызлык исемнәр, аларның дөрес язылышы. Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формалары. Күплек сан кушымчаларының дөрес язылышы, аларны рус теле белән чагыштыру. | **5** |
| 5 | **Морфология.** | **Фигыль.**Фигыльнең мәгънәсе, сораулары. Фигыльләрнең заман формалары турында төшенчә бирү. Аларны рус теле белән чагыштырып күрсәтү. | **4** |
| 6 | **Морфология.** | **Сыйфат.**Сыйфатның мәгънәсе, сораулары белән таныштыру. Предметның төрле билгеләрен белдерә торган сүзләр буларак, аларны сөйләмдә дөрес куллану. Бирелгән җөмләләрдән, әзер тексттан өйрәнгән сүз төркемнәрен табу, андый сүзләрне русчадан татарчага тәрҗемә итү, сөйләмдә дөрес куллану. | **3** |
| 7 | **Синтаксис.** | Сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзү. Җөмләнең баш кисәкләре турында мәгълүмат бирү, аларның урнашу тәртибен күзәтү, аны рус теле белән чагыштыру. Бирелгән сүзләр белән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзү күнекмәләре тәрбияләү. Тәрҗемә күнекмәләре булдыру. | **5** |
| 8 | **Сөйләм үстерү** | Тексттагы җөмләләрнең билгеле бер тәртиптә урнашуы Рәсем һәм терәк сүзләр ярдәмендә хикәя төзү.<br>Текстны үзгәртү, эчтәлеген сөйләү. | **4** |
| 9 | **Ел буена үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау** | | **6** |
| **Барлыгы:** | | | **70** |

## 3 нче сыйныф (татар теле – 70 сәгать)

| № п/п | Бүлекләр, темалар | Укыту программасының төп эчтәлеге | Сәгать саны |
|---|---|---|---|
| 1 | **2нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау** | | **8** |
| 2 | **Сүз.** | Әйтелеш һәм мәгънә бердәмлеге буларак сүз, аның туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Синонимнар, омонимнар һәм антонимнар. Аларны тексттан табу, сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллана белү.<br>Сүзлекләр турында мәгълүмат бирү һәм алар белән эшләргә өйрәтү. Сүзлек диктантлары язу. | **8** |
| 3 | **Сүз төзелеше һәм ясалышы.** | Тамыр һәм кушымча. Ясалма сүзләр. Тамырдаш сүзләр. Татар һәм рус телләрендә сүзләргә кушымчаларның ялгану тәртибе һәм үзенчәлекләре. Кушма һәм парлы сүзләр. | **12** |
| 4 | **Морфология.** | **Исем**.Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе турында мәгълүмат бирү. Борын авазларына беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | **24** |
| | | **Сыйфат.** Синоним һәм антоним сыйфатлар. Аларны сөйләмдә дөрес куллану. Сыйфатларның җөмләдәге роле. Татар телендә сыйфат белән сыйфатланмышның бәйләнеше. | |
| | | **Сан.**Санның мәгънәсе, сораулары. Аны сөйләмдә дөрес куллану. Сан белән саналмышның бәйләнеше. Сөйләмдә микъдар саннарын куллану. | |
| | | **Алмашлык.** Гомуми мәгълүмат. Алмашлыкларның мәгънәсе, килеш белән төрләнеше. Сорау алмашлыклары турында мәгълүмат бирү. | |
